ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

06 март 2017ел № 1089

Башкарма комитетның «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 2 ноябрендәге 5770 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 нчы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2016 елның 2 ноябрендәге 5770 номерлы номерлы карарына (Башкарма комитетның 2017 елның 10 гыйнварындагы 15 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 бүлекнең 8 юлын программаны финанслау күләме һәм чыганаклары түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 (мең сум) | 2018 (мең сум.) | 2019 (мең сум.) | Тормышка ашыру еллары өчен барлыгы (мең сум) |
| | Муниципаль бюджет | 7397,018 | 150 | 150 | 7697,018 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | 30000 | - | - | 30000 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |
| | Барлыгы | 37397,018 | 150 | 150 | 37697,018 |

2) 5 бүлекнең 1 бурычына түбәндәге эчтәлектәге чара өстәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Сәнәгать парклары һәм мәйданчыкларының инженерлык инфра структурасын төзү максатларында проект-смета документларын эшләүгә чыгымнарны кире кайтару | Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү идарәсе | 2017 ел | Барлыкка килгән эш урыннары саны | 35 | 135 | 135 | 175 | 7247,018 (муниципаль бюджет) | - | - | Барлыкка килгән эш урыннарының саны арту, салым түләүләре арту |

3) 5 бүлекнең барлыгы юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| Программа буенча барлыгы:<br>Федераль бюджет<br>Татарстан Республикасы бюджеты<br>Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 37397,018<br>-<br>30000,0<br>7397,018 | 150,0<br>-<br>-<br>150,0 | 150,0<br>-<br>-<br>150,0 | |

4) 6 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2017-2019 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең кече һәм урта эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү» муниципаль программасы чараларын финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре»01.13, «Милли икътисад өлкәсендә башка мәсьәләләр» 04.12 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган чаралар хисабына 7697,018 мең сум: 2017 ел – 7397,018 мең сум, 2018 ел – 150 мең сум, 2019 ел – 150 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы — В.А. Гаврилов

Башкарма комитетның
2017 елның 6 мартындагы
1089 номерлы карарына
кушымта

6 бүлек. Муниципаль программаны ресурслар белән тәэмин итү

| Финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау күләме, мең сум | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Барлыгы | Шул исәптән еллар буенча | | |
| | | 2017 ел | 2018 ел | 2019 ел |
| Федераль бюджет | - | - | - | - |
| Татарстан Республикасы бюджеты | 30000 | 30000 | | |
| Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты | 7697,018 | 7397,018 | 150,0 | 150,0 |
| Барлыгы | 37697,018 | 37397,018 | 150,0 | 150,0 |

Җирле бюджет акчаларының бер өлеше сәнәгать паркларын һәм мәйданчыкларын үстерүгә юнәлдерелә. Шәһәр бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмә Башкарма комитет карары белән раслана. Сәнәгать паркларына субсидияләр бирү кече һәм урта җитештерүләрнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен шартлар тудыра.

Республика бюджеты акчалары җиһазлар лизингын үстерү: КУЭ субъектлары («Лизинг-грант») чыгымнарын субсидияләү һәм социаль эшмәкәрлек субъектларына ярдәм итү программа чараларын гамәлгә ашыруга юнәлдерелә.

Җиһазлар лизингын үстерү: КУЭ субъектлары («Лизинг-грант») чыгымнарын субсидияләү өчен дәүләт ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын сайлап алу тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 19 июнендәге 416 номерлы карары белән расланган.

Иҗтимагый файдалы максатларга ирешүгә, гражданның тормыш шартларын яхшыртуга һәм (яки) аның төп тормыш ихтыяҗларын мөстәкыйль рәвештә тәэмин итүгә, шулай ук эш белән тәэмин итүгә, инвалидларга, өлкән яшьтәге гражданнарга һәм авыр тормыш хәлендә калган затларга ярдәм итүгә юнәлдерелгән социаль юнәлешле эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының чыгымнарының бер өлешен субсидияләү өчен Россия Федерациясе субъектына федераль

бюджеттан субсидияләр бирү конкурслы сайлап алу шартлары нигезендә гамәлгә ашырыла:

1. Федераль бюджет субсидияләре алга таба социаль эшмәкәрлек субъектларына бирү өчен Россия Федерациясе субъектларына түбәндәге шартларның берсендә бирелә:

а) социаль эшмәкәрлек субъекты инвалидларны, өлкән яшьтәге гражданнарны, авыр тормыш хәлендә калган затларны, 7 (җиде) яшькә кадәрге балалары булган хатын-кызларны, ятимнәрне, балалар йортларын тәмамлаучыларны (алга таба - социаль якланмаган гражданнар төркемнәренә караган затлар), шулай ук конкурслы сайлап алу датасына кадәр 2 (ике) ел дәвамында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны эш белән тәэмин итә, әлеге категория гражданнарның исемлек буенча уртача саны 50% тан да ким булмаган, хезмәт хакы фондындагы өлеше - 25% тан да ким булмаган очракта;

б) социаль эшмәкәрлек субъекты түбәндәге өлкәләрдә хезмәт күрсәтү (товарлар җитештерү, эшләр башкару) эшчәнлеген башкара:

- социаль якланмаган гражданнар төркемнәренә караган затларның мәшгульлегенә һәм үзмәшгульлегенә булышлык итүне дә кертеп, һөнәри ориентацияләүгә һәм эшкә урнашуга булышлык күрсәтү;

- социаль якланмаган гражданнар төркемнәренә керүче затларга һәм сәламәтлек саклау, физик культура һәм массакүләм спорт өлкәсендә балалары булган гаиләләргә социаль хезмәт күрсәтү, балалар һәм яшьләр түгәрәкләрендә, секцияләрдә, студияләрдә дәресләр үткәрү;

- социаль туризмны оештыру - социаль якланмаган төркемнәргә караган затлар өчен экскурсия-танып-белү турлары өлешендә генә;

- табигый бәла-казалар, экологик, техноген яки башка катастрофалар, социаль, милли, дини конфликтлар нәтиҗәсендә зыян күрүчеләргә, качакларга һәм күчеп китәргә мәҗбүр булучыларга ярдәм күрсәтү;

- медицина техникасы, протез-ортопедик эшләнмәләр, шулай ук автомототранспортны да кертеп, инвалидлыкны профилактикалау яки инвалидларны реабилитацияләү өчен генә файдаланыла торган техник чаралар җитештерү һәм (яки) сату;

- мәдәни-агарту эшчәнлеген тәэмин итү (музейлар, театрлар, мәктәп-студияләр, музыка учреждениеләре, иҗади остаханәләр);

- гражданнарның социаль якланмаган төркемнәренә караган затларга белем бирү хезмәтләре күрсәтү;

- социаль якланмаган гражданнар төркемнәренә караган затларны, шулай ук 2 (ике) ел дәвамында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны һәм наркоманлык һәм алкоголизмнан интеккән затларны социаль-актив эшчәнлеккә җәлеп итүгә булышлык күрсәтү.

2. Россия Федерациясе субъекты тарафыннан бирелә торган субсидияләр суммасының 15% тан да ким булмаган күләмендә

чыгымнарны финанслауны тәэмин итүче социаль эшмәкәрлек субъектына бирелә торган федераль бюджет субсидиясенең максималь күләме бер ярдәм алучыга 1,5 млн.сумнан артмый.».

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе
Г.К. Әхмәтова